КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 27 май г.Казань № 371

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясенә килгән чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга Татарстан Республикасында вакытлыча яшәүгә рөхсәт яки яшәүгә рөхсәт, яки эшләүгә рөхсәт алу яисә патент алу (яңадан рәсмиләштерү) өчен медицина тикшерүен үткәрүне (шул исәптән «бер тәрәзә» принцибы буенча) оештыру турында» 2018 ел, 13 июнь, 469 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясенә килгән чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга Татарстан Республикасында вакытлыча яшәүгә рөхсәт яки яшәүгә рөхсәт, яки эшләүгә рөхсәт алу яисә патент алу (яңадан рәсмиләштерү) өчен медицина тикшерүен үткәрүне (шул исәптән «бер тәрәзә» принцибы буенча) оештыру турында» 2018 ел, 13 июнь, 469 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган һәм чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга вакытлыча яшәүгә рөхсәт яки яшәүгә рөхсәт, яки эшләүгә рөхсәт алу яисә патент алу (яңадан рәсмиләштерү) өчен баш тартуга яисә гамәлдән чыгаруга нигез булган йогышлы авырулар исемлеген, шулай ук аларның булуын яисә булмавын раслау тәртибен, шулай ук әлеге авыруларның булуы (булмавы) турында медицина бәяләмәсе формаларын раслау турында» 2015 елның 29 июнендәге 384н номерлы» сүзләрен «Чит ил гражданында яисә гражданлыгы булмаган затта әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган йогышлы авырулар һәм кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ-инфекция) китереп чыгара торган авырулар булуга яисә булмауга медицина тикшерүен (чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат организмында наркотик чаралар яисә психотроп

матдәләр яисә яңа потенциаль куркыныч психоактив матдәләр һәм аларның метаболитлары булуына химик-токсикологик тикшеренүләр үткәрүне кертеп) үткәрү тәртибен, табиб билгеләмәгән наркотик чаралар яисә психотроп матдәләр йә яңа потенциаль куркыныч психоактив матдәләр куллану факты булмау турында медицина бәяләмәсе бланкы формасын һәм аның гамәлдә булу срогын, шулай ук әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган йогышлы авырулар булуы (булмавы) турында медицина бәяләмәсе формасын, аның бланк тасвирламасын һәм гамәлдә булу срогын раслау турында» 2021 елның 19 ноябрендәге 1079н номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Россия Федерациясенә килгән чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга Татарстан Республикасында вакытлыча яшәүгә рөхсәт яки яшәүгә рөхсәт, яки эшләүгә рөхсәт алу яисә патент алу (яңадан рәсмиләштерү) өчен медицина тикшерүен үткәрүне (шул исәптән «бер тәрәзә» принцибы буенча) гамәлгә ашырырга вәкаләтле медицина оешмалары исемлегенә түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6. «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең медик-санитар часте.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин